РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 ноябрь 2022 ел Буа шәһәре № 3-37

Хезмәт (вазифа) тәртибенә карата таләпләрне
үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу
буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

1. «Хезмәт (вазифа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Буа муниципаль районы Советының 2018 елның 07 августындагы 8-33 номерлы карары белән расланган Хезмәт (вазифа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә ( алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«3.2.5. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне, яки әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерләгәндә, комиссия мөрәҗәгатьне яки хәбәрнамәне тапшырган муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә уздырырга, аннан язма аңлатмалар алырга, ә махсус вәкаләте булган җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә аның урынбасары, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрергә, коррупциягә каршы тору өлкәсендә "Посейдон" дәүләт мәгълүмат системасын кулланырга (шул исәптән запрослар җибәрү өчен дә) хокуклы. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар килгән

көннән алып җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Запрослар җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү кергән көннән 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артыкка түгел.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов